СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2022 елның «12» августы

Алабуга шәһәре

№ 186

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2017 елның 28 августындагы 198 номерлы "Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре һәм аларның гаилә әгъзалары керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Алабуга муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны Бөтенроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында"гы карарына үзгәрешләр кертү турында

2012 елның 3 декабрендә кабул ителгән 230-ФЗ номерлы "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" гы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны Бөтенроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында 2017 елның 28 августындагы 198 номерлы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктындагы 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"муниципаль вазыйфаны биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч ел эчендә гомуми кеременнән артып китсә, җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, (оешмаларның устав (туплау) капиталларында катнашу өлеше), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-биреш эшләре башкарылган акчаларны алу чыганаклары һәм алыш-бирешләр кылганчы өч ел эчендә акча алу чыганаклары турында мәгълүматлар";.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Новая Кама» газетасында, «Алабуга Нуры» газетасында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук городелабуга.рф. рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль төзелеш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Рәис урынбасары О. Е. Колпаков